КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 май г.Казань № 347

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 18 июнь, 412 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 851 нче; 2017 ел, 23 июнь, 417 нче; 2018 ел, 14 июнь, 472 нче; 2019 ел, 13 июнь, 487 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 748 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 926 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 993 нче; 2020 ел, 11 февраль, 86 нчы; 2020 ел, 9 апрель, 264 нче; 2020 ел, 30 апрель, 353 нче; 2020 ел, 28 сентябрь, 878 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

«Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы» бүлекчәсендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «2. | Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны миграция исәбенә алуны гамәлгә ашыру»; |

7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

«Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «20. | Транспорт салымы буенча салым салу объектының һәлакәте яки юк ителүе турында гариза кабул итү»; |

II бүлектә:

II бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарының хезмәт күрсәтүләре»;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2. | Кара металлар, төсле металллар калдыкларын хәзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле чараларын үткәрүгә җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү»; |

«Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «3. | Татарстан Республикасы территориясендә табылган яки тиешле рөхсәтнамәсез сакланган корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен түләүне гамәлгә ашыруга документлар кабул итү»; |

түбәндәге эчтәлекле бүлекчә өстәргә:

| «Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе | |
|---|---|
| 1. | Гражданнарның «Суд эшчәнлеге» Россия Федерациясе дәүләт автоматлаштырылган системасыннан файдалану мөмкинлеге юлы белән күпфункцияле үзәкләр аша электрон рәвештә гомуми юрисдикция судларына документлар бирү һәм гомуми юрисдикция судыннан документлар алу мөмкинлеген тәэмин итү |

IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 55 – 60 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «55. | Гражданның судтан тыш бөлгенлеккә төшү процедурасын гамәлгә ашыру |
| 56. | Яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясау өчен гражданны көтү кәгазенә кертү |
| 57. | «Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыятенең хезмәт күрсәтүләре буенча консультация бирү |
| 58. | Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозулар өчен штрафлар булу яки булмау турында мәгълүмат бирү |
| 59. | Полиграфия продукциясен тарату |
| 60. | Клиент карталарын тарату (рәсмиләштерү) (дисконт картасы, ташлама картасы, купон, ваучер, талон һәм башка шундыйлар)»; |

V бүлеккә түбәндәге эчтәлекле бүлекчә өстәргә:

| «Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыяте | |
|---|---|
| 1. | «Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыятенең хезмәт күрсәтүләре буенча консультация бирү (мәгълүмат бирү). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин